СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,42319

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы

Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАРЫ

2019 елның 5 июленнән № 50-296

"2017 – 2020 елларга Яңа Чишмә муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасын 2018 елда гамәлгә ашыру барышы һәм 2019 елга бурычлар турында.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары В.Н. Семенякның «2017-2020 елларга Яңа Чишмә муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасын гамәлгә ашыруның барышы һәм 2019 елга бурычлар турында мәгълуматын тыңлаганнан соң, "Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

«2017-2020 елларга Яңа Чишмә муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» турындагы мәгълүматны игътибарга алырга.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

телләрне һәм мәдәниятне саклау һәм үстерү өчен шартлар тудырырга, Яңа Чишмә муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру кысаларында район җирлекләре территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының рухи һәм мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрүгә булышлык күрсәтергә;

милләтара һәм конфессияара килешүне ныгытуга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудырырга һәм авыл җирлекләре Советлары утырышларында әлеге мәсьәләләр буенча фикер алышу практикасын кертергә;

2.3. мигрантларны социаль һәм мәдәни адаптацияләү өчен шартлар тудырырга, Дәүләт, хокук саклау структуралары вәкилләре һәм муниципаль берәмлекләр территориясендә яшәүче диаспоралар катнашында миграция сәясәте мәсьәләләре буенча даими рәвештә "түгәрәк өстәлләр" уздырырга.

3. Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

3.1. милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр торышы һәм юнәлешләрен ачыклау максатында, квартал саен мониторинг үткәрергә;

3.2. район территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыклары вәкилләре катнашында массакүләм чаралар үткәрергә;

3.3. этникара, конфессияара мөнәсәбәтләрне исәпкә алып, истәлекле вакыйгаларга багышланган чаралар үткәрергә;

3.4. 2019 елның 30 сентябренә кадәр срокка район территориясендә яшәүче халыкларның тарихи һәйкәлләре белән танышуны исәпкә алып, муниципаль юл картасын һәм авыл туризмы маршрутын эшләргә;

3.5. район территориясендә урнашкан мәдәният һәйкәлләре реестрын алып барырга һәм саклап калу өчен чаралар күрергә;

3.6. татар халкының республика һәм районнан читтә милли үзенчәлеген саклау һәм үстерү өчен шартлар тудыруда ярдәм күрсәтергә;

3.7. патриотизм һәм гомумроссия гражданнар тәңгәллеген формалаштыруга һәм ныгытуга юнәлдерелгән иҗтимагый инициативаларга һәм чараларны үткәрүгә ярдәм итәргә.

4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлегенә тәкъдим итәргә:

4.1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында татар, рус һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү өчен шартлар тудырырга;

4.2. Татарстан Республикасы һәм Россия территориясендә яшәүче халыклар турында белемнәрне таратуга юнәлдерелгән белем бирү чараларын тормышка ашырырга.

5. Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып баручы иҗтимагый берләшмәләргә тәкъдим итәргә:

5.1. дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән чаралар һәм программаларны оештыруда һәм үткәрүдә катнашу буенча эшне активлаштырырга;

5.2. төрле этномәдәни һәм спорт чаралары, хәйрия акцияләре үткәрү юлы белән, шул исәптән яшьләр һәм мәктәп мохитендә дә, милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне саклауда актив катнашырга;

5.3 милләтара мөнәсәбәтләрне гармонияләштерүгә һәм мәдәниятара диалогны үстерүгә юнәлдерелгән проектларны тормышка ашыру өчен грантлар алу хокукына конкурста активрак катнашырга.

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырырга (халыкка игълан итәргә).

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Яңа Чишмә муниципаль районы Советының социаль сәясәт буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы
Башлыгы В.М. Козлов